**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Кайбыч авыл җирлегенең Иске Чәчкаб торак пунктында**

**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

26 октябрь, 2019 № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә,Татарстан Республикасы Кайбычмуниципальрайонының Олы Кайбыч авыл җирлегенең Иске Чәчкаб торак пунктында гражданнар җыены КАРАР КЫЛДЫ:

1. 2020 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Кайбыч авыл җирлегенең Иске Чәчкаб авылы территориясендә даими яшәүче һәм яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 500 (биш йөз) сумм күләмендә үзара салым акчаларын кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга тотарга:

а) җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:

- материаллар сатып алып, Иске Чәчкаб авылы буасын чистарту һәм төзекләндерү,

- материаллар сатып алып, урам утларын ремонтлау;

- җирлектәге торак пунктлардагы чүплекләрне чистарту;

б) җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:

- материаллар сатып алып, су челтәрләрен ремонтлау;

в) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- материаллар сатып алып, юлларны норматив хәлгә китерү;

- җирлекнең торак пунктлары чикләрендә автомобиль юлларын карап тоту;

г) ритуаль хезмәтләр оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту:

- материаллар сатып алып, зиратларны чистарту һәм ремонтлау.

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларына, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Кайбыч авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Олы Кайбыч авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе Р.Б. Сафин